СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 4-30 от « 27 » мая 2024 г.

**Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 79 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 28_1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 23 мартындагы 54-ФЗ номерлы федераль законнар, , Татарстан Республикасы "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә ( Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 ел, 12 ноябрь, № 3-12, 2017 ел, 12 май, № 8-16, 2017 ел, 26 июль,№ 4-18 , 2017 ел, 13 ноябрь, № 4-19, 2018 ел, 29 июнь,№ 10-27, 2018 ел, 3 сентябрь, № 8-28, 2018 ел, 19 ноябрь,№ 11-29 2019 ел, 28 март, № 8-32, 2019 ел, 23 июль, № 17-34, 2020 ел, 30 июнь, № 12-39, 2020 ел, 15 декабрь, № 7-4, 2021 ел, 10 июнь, № 8-7, 2021 ел, 12 ноябрь, № 13-9, 2022 ел, 11 август, № 13-15, 2023 ел, 26 апрель, № 18-21, 28 июль 2023 ел, № 11-22, 2023 ел, 14 ноябрь, № 2-24 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25.7 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белемне тәүге тапкыр алучы һәм уку тәмамлангач хезмәт мөнәсәбәтләрен барлыкка китерүче

укучы шартнамәсе яисә башка шартнамә буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия.";

1.2. 12.4 пунктта "мәгълүмат" сүзеннән соң "(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)"сүзләрен өстәргә;

1.3 12.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;

1.4. 7.1. пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8) муниципаль хезмәткә урнашканда һәм (яисә) аны узу чорында чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүнераслаучы ялган документлар һәм (яисә) белә торып ялган белешмәләр тапшырса, яки чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрнеүтәмәүне дәлилли торган документлар һәм (яисә) белешмәләр тапшырмаса;";

1.5. Пункт 6.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт өстәргә:

"13) әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрдәге ( алаг таба- анкетадагы белешмәләр) аңа билгеле булган үзгәрешләр турында, яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итәргә,";

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов